| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 Баулы шәһәре № 232

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142нче маддәсе нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен расларга турында.

2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының бюджет һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы Советының
2019 елның 03.12. кабул ителгән
232 номерлы карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетыннан Баулы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәү максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга, шул исәптән грантлар, матди кызыксындыру, үзара салым акчаларын, учреждениеләрнең яңа челтәрен тотуга һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча бүлеп бирелә торган башка чараларны тотуга Баулы муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) исәбеннән бирелә.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2нче пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Башка бюджетара трансфертлар, төзелгән килешүләр нигезендә, шәһәр, авыл җирлекләренеж җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен финанс белән

тәэмин итүгә җибәрелә.

7. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге критерийларга җавап бирә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә:

а) район Башкарма комитеты белән кул куелган килешү булуы;

б) Башкарма комитет тарафыннан раслана торган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза булу.

в) шәһәр һәм авыл җирлекләре территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләренә туры килә торган объектлар булу.

8. Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары булып тора:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 13нче пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;

б) шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44нче статьясында каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү;

в) муниципаль берәмлекнең бюджетында (җыелма бюджет язмасында) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу (акча аларны финанслашу максатларында, аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә бирелә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган башка бюджетара трансфертларны да кертеп);

9. Район башкарма комитеты районның финанс-бюджет палатасына акча күчерү вәкаләтләрен тапшыра.

10. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән вакытта, җирлек башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны финанс-бюджет палатасына тапшыра:

Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза;

хезмәтләр, товарлар (материаллар) сатып алуга акча ихтыяҗын раслый торган документлар(шартнамәләр, контрактлар, башкарылган эшләр актлары).

11. Җирлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары район Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә.

12. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана.

13. Башка бюджетара трансфертларны бирү район Башкарма комитеты һәм вәкаләтле орган арасында Башкарма комитет тарафыннан расланган формалар нигезендә төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Килешүдә карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре - бу максатларга акча бирү турында район башкарма комитетының норматив-хокукый актларында күрсәтелә торган параметрларга ирешү.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү, вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган хисаплылыкка үткәрелгән анализ нигезендә, Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

16. Вәкаләтле органнар килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны Башкарма комитетка тапшыралар.

17. Район башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык вәкаләтле органга йөкләнә.

18. Район финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

19. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты keременә күчерелергә тиеш.

20. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләп нигезендә муниципаль район бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

21. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Тәртипнең 2нче пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

22. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.